# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2020 елның 20 октябре** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- Алан-Бәксәр авылында су алу скважинасының санитар саклау зонасын койма белән әйләндереп алу (территориясен киңәйтү) (материал сатып алу, килешү буенча түләү);

- Алан-Бәксәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тоту (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру);

- Алан-Бәксәр авыл мәдәният йорты янындагы ял зонасы территориясен төзекләндерүне (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча 2020 елның 20 октябрендә 14 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 220 (Ике йөз егерме) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 114 кеше, бу 51,8 % тәшкил итә;

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 114 (Йөз ундүрт) кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 (ноль) катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2021 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Алан-Бәксәр авылында су алу скважинасының санитар саклау зонасын койма белән әйләндереп алу (территориясен киңәйтү) (материал сатып алу, килешү буенча түләү);

- Алан-Бәксәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тоту (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру);

- Алан-Бәксәр авыл мәдәният йорты янындагы ял зонасы территориясен төзекләндерүне (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы — З. Р. Гарифуллина

Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы
Совет Алан-Бексерского сельского поселения
ИНН 1616000659